КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 6 май г.Казань № 421

Мәгълүмат технологияләрен (программа продуктларын) һәм мәгълүмат базаларын аерым исәпкә алу һәм аларның кыйммәтен бәяләү методикасын раслау турында

Мәгълүмат системаларын һәм мәгълүмат базаларын булдыру һәм аларны Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары, аларның ведомство буйсынуындагы оешмалары эшчәнлегендә файдалану (мәгълүмат технологияләрен (программа продуктларын) булдыру һәм алардан файдалану өлешендә) нәтиҗәлелеген күтәрү максатларында, шулай ук аларны сатып алу, эшләү һәм модернизацияләү буенча хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар системасын камилләштерү өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Мәгълүмат технологияләрен (программа продуктларын) һәм мәгълүмат базаларын аерым исәпкә алу һәм аларның кыйммәтен бәяләү методикасын (алга таба – Методика) расларга.

2. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарына, аларның ведомство буйсынуындагы оешмаларына үз эшчәнлегендә Методикага таянып эш итәргә.

3. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына һәм аларның ведомство буйсынуындагы оешмаларына мәгълүмат системаларын булдырганда, аларның эшләвен тәэмин иткәндә һәм алардан файдаланганда, шулай ук мәгълүмат технологияләрен (программа продуктларын) һәм мәгълүмат базаларын сатып алганда, эшләгәндә, модернизацияләгәндә Методикага таянып эш итүне тәкъдим итәргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 6 май, 421 нче карары белән расланды

# Мәгълүмат технологияләрен (программа продуктларын) һәм мәгълүмат базаларын аерым исәпкә алу һәм аларның кыйммәтен бәяләү методикасы

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Бу Мәгълүмат технологияләрен (программа продуктларын) һәм мәгълүмат базаларын аерым исәпкә алу һәм аларның кыйммәтен бәяләү методикасы (алга таба – Методика) матди булмаган активлар объектлары буларак мәгълүмат технологияләрен (программа продуктларын) һәм мәгълүмат базаларын исәпкә алуга һәм аларның кыйммәтен бәяләүгә карата бердәм таләпләрне һәм аларның тәртибен билгеләүне тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары, аларның ведомство буйсынуындагы оешмалар тарафыннан файдалану өчен билгеләнгән.

1.2. Методика бухгалтерлык исәбенең федераль стандартлары, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы боерыклары һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә эшләнгән.

1.3. Әлеге Методика максатларында түбәндәге терминнар кулланыла:

матди булмаган актив – сатып алганда (булдырганда) исәпкә алу субъектының махсус хокуклары, лицензия шартнамәләре яисә мондый активка хокук булуны раслый торган башка документлар нигезендә хокуклары барлыкка килгән башка мөлкәттән идентификацияләү (бүлү, аеру) мөмкинлеге белән учреждение эшчәнлегендә берничә тапкыр һәм (яки) 12 айдан артык даими файдалану өчен билгеләнгән, матди һәм әйберләтә формасы булмаган, финанс булмаган активлар объекты;

матди булмаган активлар төркеме – бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгында гомумиләштерелгән күрсәткеч белән мәгълүматы ачыла торган матди булмаган активлар җыелмасы;

функциональ заказчы – мәгълүмат технологияләрен (программа продуктларын) һәм мәгълүмат базаларын булдыруга, модернизацияләүгә һәм (яки) сатып алуга ихтыяҗны билгели торган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы;

дәүләт заказчысы – Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә бюджет йөкләмәләрен кабул итәргә вәкаләте булган һәм функциональ заказчы ихтыяҗлары өчен мәгълүмат технологияләрен (программа продуктларын) һәм мәгълүмат базаларын сатып алуны (аларны модернизацияләүне кертеп) гамәлгә ашыра торган «Татарстан Республикасы Цифрлы трансформация үзәге» дәүләт казна учреждениесе (алга таба – «ТР ЦТҮ» дәүләт казна учреждениесе);

бу Методикада кулланыла торган башка төшенчәләр «Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре һәм мәгълүматны яклау турында» 2006 елның 27 июлендәге

149-ФЗ номерлы Федераль законда һәм «Татарстан Республикасының мәгълүмат системалары һәм мәгълүматлаштыру турында» 2007 елның 13 ноябрендәге 58-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән мәгънәләрдәге кебек кулланыла.

1.4. Мәгълүмат системасын һәм бүлеп чыгарылган очракта – мәгълүмат технологияләрен (программа продуктларын) һәм мәгълүмат базаларын идентификацияләү уникаль идентификация коды нигезендә гамәлгә ашырыла. Әлеге код барлык мәгълүмат системаларында һәм бүлеп чыгарылган очракта – мәгълүмат технологияләрендә (программа продуктларында) һәм мәгълүмат базаларында кулланыла, анда мәгълүмат системасы, мәгълүмат технологияләре (программа продуктлары) һәм мәгълүмат базалары белешмәләре турында мәгълүмат чагылыш табачак. Уникаль идентификация коды әлеге объектларны Татарстан Республикасы мәгълүмат системаларының бердәм реестрында теркәгәндә бирелә. Мәгълүмат системасын һәм бүлеп чыгарылган очракта – мәгълүмат технологияләрен (программа продуктларын) һәм мәгълүмат базаларын идентификацияләү уникаль идентификация коды нигезендә гамәлгә ашырыла. Әлеге код барлык мәгълүмат системаларында һәм бүлеп чыгарылган очракта – мәгълүмат технологияләрендә (программа продуктларында) һәм мәгълүмат базаларында кулланыла, анда мәгълүмат системасы, мәгълүмат технологияләре (программа продуктлары) һәм мәгълүмат базалары белешмәләре турында мәгълүмат чагылыш табачак. Уникаль идентификация коды әлеге объектларны Татарстан Республикасы мәгълүмат системаларының бердәм реестрында теркәгәндә бирелә.

1.5. Мәгълүмат технологиясе (программа продукты) һәм мәгълүмат базасы Россия Федерациясе Граждан кодексы нигезендә интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләренә кертеп карала.

1.6. Әгәр мәгълүмат технологиясе (программа продукты) һәм мәгълүмат базасы башка активлардан бүлеп яки аерылып алынса (идентификацияләнсә) (шул исәптән аларны сатып алганда (булдырганда) оешманың мондый активларга карата махсус хокуклары, лицензия шартнамәләре яисә мондый активның булуын һәм аңа хокукны раслый торган башка документлар нигезендә файдалану хокуклары барлыкка килсә), алар беренчел кыйммәте буенча матди булмаган аерым активлар буларак исәпкә алына. Әлеге шарт интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләренең катлаулы объектларына, электрон исәпләү машиналары программаларының функциональ өлешләренә, мәгълүмат базалары белән идарә итү системаларына (аларның махсус хокуклары мәгълүмат системаларын булдыру яки модернизацияләү турындагы контрактны үтәү нәтиҗәсендә сатып алынган) карата кулланылмый.

Мәгълүмат системалары составына керә торган, документаль рәвештә рәсмиләштерелмәгән интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләрен аерым исәпкә алу турында карар Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы боерыгы нигезендә кабул ителә.

## II. Матди булмаган активлар объектларын (мәгълүмат технологияләрен (программа продуктларын) һәм мәгълүмат базаларын исәпкә алуга кабул итү

2.1. Матди булмаган активлар объектлары (мәгълүмат технологияләре (программа продуктлары) һәм (яки) мәгълүмат базалары) исәпкә алу субъекты тарафыннан аларны файдаланудан икътисадый файдалар яки файдалы потенциал алырга планлаштырылу һәм мондый объектларның беренчел кыймматен бәяләү мөмкинлеге шарты белән матди булмаган активлар төркеме составында бухгалтерлык исәбенә алынырга тиеш.

2.2. Матди булмаган активлар объектлары милекче (гамәлгә куючы) тарафыннан аңа беркетелгән әлеге активларны да, аның тарафыннан финанс-хуҗалык эшчәнлеге барышында алынган активларны да фактта файдалана торган (файдаланырга хокукы булган) шул ук исәпкә алу субъектының бухгалтерлык исәбенә алына.

2.3. Матди булмаган активларның (мәгълүмат технологияләренең (программа продуктларының) һәм мәгълүмат базаларының) кайбер объектларын аерым исәпкә алу 1.6 пунктта билгеләнгән очракларда гамәлгә ашырыла, шул ук вакытта:

а) функциональ заказчы тарафыннан мәгълүмат системасының мәгълүмат базасы (яки подрядчы белән килешү нигезендә) мөстәкыйль рәвештә булдырылган очракта, ул аны мөстәкыйль рәвештә балансака куярга һәм лицензия шартнамәсе буенча файдалану хокукын «ТР ЦТҮ» дәүләт казна учреждениесенә тапшырырга тиеш;

б) мәгълүмат системасының мәгълүмат базасы «ТР ЦТҮ» дәүләт казна учреждениесе тарафыннан (яки подрядчы белән килешү нигезендә) булдырылган очракта, функциональ заказчының рәсми соравы буенча Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы боерыгы нигезендә «ТР ЦТҮ» дәүләт казна учреждениесе әлеге мәгълүмат базасын балансака куюны гамәлгә ашыра һәм мәгълүмат базасыннан файдалану хокукын функциональ заказчыга тапшыра.

2.4. Сатып алынган һәм булдырылган (шул исәптән подряд (субподряд) оешмасын җәлеп итеп) мәгълүмат технологияләре (программа продуктлары) «ТР ЦТҮ» дәүләт казна учреждениесенә тапшырыла һәм «ТР ЦТҮ» дәүләт казна учреждениесенең матди булмаган активы буларак бухгалтерлык исәбенә алына.

2.5. Мәгълүмат технологияләре (программа продуктлары) белән бергә (башлангыч кодны һәм объект кодын кертеп (әгәр дә бу мәгълүмат технологиясенә (программа продуктына) һәм мәгълүмат базасына махсус хокукларны читләштерү турындагы шартнамәдә каралган булса), түбәндәгеләр «ТР ЦТҮ» дәүләт казна учреждениесенә тапшырыла:

әзерлек (проект) документациясе: мәгълүмат технологияләрен (программа продуктларын) эшләүгә техник бирем; аңлатма язуы, функциональ структура функцияләренең, схемасының гомуми тасвирламасы һәм мәгълүмат технологиясе (программа продукты) тасвирламасы составында мәгълүмат технологияләре (программа продукты) өчен программаның техник проекты;

мәгълүмат технологиясе (программа продукты) тасвирламасы составындагы техник документация;

мәгълүмат технологиясе (программа продукты) өчен программаның өйрәтү һәм презентация материаллары һәм (яки) скриншотлары бирелгән ияртүле документация һәм (яки) норматив хокукый актлар һәм (яки) мәгълүмат технологиясен (программа продуктын) файдалану өчен кирәкле оештыру-боеру характерындагы документлар турында белешмәләр бирелгән методик документация (булганда).

2.6. Функциональ заказчы «ТР ЦТҮ» дәүләт казна учреждениесе өчен мәгълүмат базаларына керү мөмкинлеген билгеләнгән тәртиптә тәэмин итә.

2.7. Булдырылган мәгълүмат технологияләре (программа продуктлары) һәм (яки) мәгълүмат базалары Россия Федерациясе Финанс министрлыгының «Матди булмаган активлар» дәүләт финансларын бухгалтерлык исәбенә алуның федераль стандартын раслау турында» 2019 ел, 15 ноябрендәге 181н номерлы боерыгы белән расланган кагыйдәләр (алга таба – Матди булмаган активларны исәпкә алу стандарты) буенча исәпкә алына һәм матди булмаган актив буларак бухгалтерлык исәбенә алына.

## III. Матди булмаган активлар (мәгълүмат технологияләре (программа продуктлары) һәм мәгълүмат базалары) кыйммәтен бәяләү

3.1. Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен сатып алулар, товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр өлкәсендә контракт системасы турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә мәгълүмат технологияләрен (программа продуктларын) эшләү яки кулланыла торганнарын модернизацияләү буенча хезмәт күрсәтүне сатып алу эшчәнлеген оештырганда, мәгълүмат технологияләрен (программа продуктларын) эшләү яки кулланыла торганнарын модернизацияләү кыйммәте, аларны гамәлгә ашыру сроклары һәм контрактның башлангыч (максималь) бәясен формалаштыру Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 7 август, б-1504 нче боерыгы белән расланган Программа продуктын эшләү һәм аның эшләвен тәэмин итү кыйммәтен һәм аларның бик күп көч куюны таләп итүен бәяләү буенча методик тәкъдимнамәләр нигезендә билгеләнә.

3.2. Финанс булмаган активлар объектлары буларак мәгълүмат технологияләренең (программа продуктларының) беренчел кыйммәте, Россия Федерациясе Финанс министрлыгының «Дәүләт хакимияте органнары (дәүләт органнары), җирле үзидарә органнары, бюджеттан тыш дәүләт фондларының идарә органнары, дәүләт фәннәр академияләре, дәүләт (муниципаль) учреждениеләре өчен бухгалтерлык исәбе счетларының бердәм планын раслау һәм аны куллану инструкциясе турында» 2010 елның 1 декабрендәге 157н номерлы боерыгы белән расланган Дәүләт хакимияте органнары (дәүләт органнары), җирле үзидарә органнары, бюджеттан тыш дәүләт фондларының идарә органнары, дәүләт фәннәр академияләре, дәүләт (муниципаль) учреждениеләре өчен бухгалтерлык исәбе счетларын куллану инструкциясе таләпләрен һәм Россия Федерациясе Финанс министрлыгының«Матди булмаган активлар» дәүләт финансларын бухгалтерлык исәбенә алуның федераль стандартын раслау турында» 2019 елның 15 ноябрендәге 181н номерлы боерыгы белән расланган «Матди булмаган активлар» дәүләт финансларын бухгалтерлык

исәбенә алуның федераль стандарты нигезләмәләрен исәпкә алып, бухгалтерлык исәбенә алына.

Исәпкә алу субъекты тарафыннан милекчедән (гамәлгә куючыдан), бюджет өлкәсенең башка оешмасыннан алынган матди булмаган активлар объектлары тапшыру документларында чагылдырылган кыйммәт буенча тапшыра торган як тарафыннан билгеләнгән бәядә бухгалтерлык исәбендә исәпләнергә тиеш.

3.3. Әгәр матди булмаган активлар (мәгълүмат технологияләре (программа продуктлары) һәм (яки) мәгълүмат базалары) модернизацияләнгән булса, аларның беренчел (баланс) кыйммәте модернизацияләү нәтиҗәсендә тотылган факттагы чыгымнар күләменә арттырылырга тиеш.

## IV. Матди булмаган активларны (мәгълүмат технологияләрен (программа продуктларын) һәм мәгълүмат базаларын) амортизацияләү

4.1. Россия Федерациясе Финанс министрлыгының «Матди булмаган активлар» дәүләт финансларын бухгалтерлык исәпкә алуның федераль стандартын раслау турында» 2019 елның 15 ноябрендәге 181н номерлы боерыгы нигезендә амортизация методы киләчәктә икътисадый файда яисә матди булмаган активларда (мәгълүмати технологияләр (программа продуктлары) һәм мәгълүмат базаларында) булган файдалы потенциал алуның күздә тотылган ысулын чагылдыра.

Амортизация файдалы файдалану өчен билгеләнгән сроклы матди булмаган активлар объектлары буенча исәпләп чыгарыла.

4.2. Исәпкә алу субъекты матди булмаган активлар (мәгълүмат технологияләре (программа продуктлары) һәм мәгълүматлар базасы) өчен киләчәктә икътисади файда яки файдалы потенциал алуның күздә тотылган ысулын төгәлрәк чагылдыра торган амортизация ысулын сайлап ала.